РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

---

Решение　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Карар

2019 елның 27 декабре　　　Чистай шәһәре　　　　　№ 51/4

2020 елга Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге милкендәге
мөлкәтне хосусыйлаштыруның
Фараз планы (программасы) турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Чистай муниципаль районы Советы

Карар бирә:

1. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. 2020 елга «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru), Россия Федерациясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торгларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтында (torgi.gov.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　　　Д.А. Иванов

Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 27 декабрендәге 51/4 номерлы карарына кушымта

2020 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. 2020 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2020 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милеккә идарә итүнең нәтиҗәлелелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3 «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны аукционда яисә конкурста сату юлы белән һәм законда каралган башка ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт.

2.1. 2020 елда муниципаль казнадагы һәм Чистай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмалардан файдаланудагы муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

| т/н | Объект исеме | Урыны | Мәйданы, | | Хосусыйлаштыруны фаразлау |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | бъект | Җир кишәрлеге | |
| 1. | Торак булмаган бина, административ бина | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре,.К.Маркс ур, 13А | 79,5 | 429,3 | 1-2 кв. |
| 2. | Торак булмаган бина, 1 нче остаханә бинасы | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Бебель ур, 106 | 29,3 | 400 | 1-2 кв. |
| 3. | Торак булмаган бина, 2 нче остаханә | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Бебель ур.,106 | 28,2 | 211 | 1-2 кв. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бинасы | | | | |
| 4. | Торак булмаган бина, кухня | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Л.Толстой ур, 90Б | 2,1 | 13 3,2 | 1-2 кв. |
| 5. | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы Чистай районы, Чулпан авылы, Театр ур.,11-а | 0,9 | 71 81 | 2-3 кв. |
| 6. | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Югары Кондрата авылы, Үзәк ур., 37 | 02,4 | 30 37,7 | 2-3 кв. |
| 7. | Торак булмаган бина, склад | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Югары Кондрата авылы, Үзәк ур., 37 | 9,9 | | 2-3 кв. |
| 8. | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Тукай ур., 17 | 06,9 | | 2-3 кв. |
| 9. | Торак булмаган бина, балалар бакчасы | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Талкышы авылы, Совет ур., 5/1 | 21,2 | 24 85,9 | 3-4 кв. |
| 10. | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Талкышы авылы, Совет ур., 5/2 | 6,3 | | 3-4 кв. |
| 11. | Торак булмаган бина, мәктәп | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Үзәк ур.,20-б | 01,9 | 7 065 | 3-4 кв. |
| 12. | Торак булмаган бина, котельный | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Үзәк ур.,20-б | 3,4 | | 3-4 кв. |
| 13. | Торак булмаган бина, остаханә | Татарстан Республикасы, Чистай районы, Ислэй авылы, Үзәк ур.,20-б | 2,7 | | 3-4 кв. |

2.3. 2020 елда муниципаль милектәге муниципаль унитар предприятиеләрне һәм акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. Муниципаль милекне, шул исәптән мондый мөлкәтне, җир кишәрлекләрен сатып алучы һәм алардан файдалану өчен кирәкле булган затны читләштерү белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла торган мөлкәтне хосусыйлаштыру турында карар, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карарлары нигезендә, Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

## 3 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

3.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә тарату һәм реклама белән киңрәк тәэмин итү максатыннан, Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы әлеге прогноз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.